Пәнҗешәмбе, 12 Март 2015 19:43

# Кремль яр буе гөрләп торачак



**Казансуның сул яр буен халык иң яраткан ял урыны итәргә ниятлиләр. Инде узган елда Казан милли мәдәни-үзәгеннән алып Батурина урамына кадәрге су буенда төзекләндерелгән һәм яшелләндерелгән зона барлыкка килде. Планнар исә Самараны да уздырып, башкалабыздагы яр буен иң озын ял-күңел ачу урыны итү.**

Белүебезчә, моңа кадәр республикабызда төзекләндерелгән яр буе Чаллыда гына бар иде. Анысы да әллә ни озын түгел – 2 километр тирәсе генә. Илебездә исә су янында ял итү өчен иң зур территория Самарада – ул 4 километрга сузыла.

Ә менә елга буенда урнашкан мәркәзебез Казанның яр буе ни сәбәпледер бик озак игътибарсыз торды. Шундый яхшы мөмкинлекләргә ия була торып, алардан файдаланмау дөрес хәл түгел, билгеле. Республика җитәкчелеге дә шул ук фикергә килеп, 2012 елда Казансуның сул ярын тәртипкә китерү турында карар кылды. Узган елда инде казанлылар башкарылган эшләрнең нәтиҗәсен күрә алды.



Шулай да гади кеше биредә башкарылган эш күләмен аңлап бетерми. Төзек яр буе, аннан ачылган матур күренешләр, шунда ук булдырылган яшел газоннар, утыртылган агачлар җәяүлеләр һәм велосипедта йөрү юллары, куелган яктырту җиһазлары, куркынычсызлык чаралары - күзгә күренгәне генә. Алдан исә Федосеев дамбасын төзекләндерү эше башкарыла. Яр буен ныгыту конструкцияләре барлыкка килә. Шуннан соң гына ял зонасы булдыру буенча эшчәнлек башлана.



Универсиада алдыннан “Казан” милли мәдәни-үзәгеннән алып Батурина урамына кадәрге 1,4 километрга сузылган яр буе беренче ял итүчеләрне каршы алды. Узган елда исә биредә хайдайвинг буенча ярышлар белән дә хозурланып булды. Быел Казансуның бу яр буеннан “Казан” гаилә үзәгенә кадәр Су төрләре буенча Дөнья чемпионаты спортчыларының ачык судагы ярышлары узачак. Махсус шуның өчен хәзерге вакытта елганы тирәнәйтү буенча эшләр башкарыла. Елга төбендәге грунт исә чыгарылып тормый, бу балчык Казансуда ике ясалма утрау барлыкка китерәчәк, дип хәбәр итте яр буен төзекләндерү белән шөгыльләнүче оешма - Казан җитештерү-төзелеш берләшмәсе генераль директоры **Равил Җиһаншин**.



Аның сүзләренчә, Казансуда утраулар болай да бар, алар су дәрәҗәсе төшкән вакытта күренә. Әмма алар нигездә бер дә матур күренеш тудырмый – елга уртасында балчык өеме кебек кенә кабул ителә. Ясалма утрауларга исә чирәм чәчеп, аларга аланнар рәвеше кертү ниятләнә. Әгәр дә халык ул утрауларга барырга теләсә, бәлки, махсус күперләр дә булдырылыр әле.

“Казан” җитештерү-төзелеш берләшмәсе матбугат үзәге җитәкчесе **Шамил Садыйков** хәбәр иткәнчә, быел су янында ял итү зонасы тагын да озынаеп, 3 километрга җитәчәк. Казан милли-мәдәни үзәгеннән алып Миллениум күперенә кадәр биләмәне көннәр җылынып, карлар эреп беткәч, төзекләндерү эшенә керешәчәкләр. Яр буен ныгыту эшләре биредә инде төгәлләнгән.



- Казанлылар һәм кунаклар өчен Кремль яр буенда ял итү һәм күңел ачу өчен төрле мөмкинлекләр тудырылачак. Машиналарда килүчеләр өчен дүрт парковка төзеләчәк, рестораннарга һәм кафеларга кереп тамак ялгый алачак, шулай ук балалар ял зонасы оештыру да ниятләнә. Яр  буе яшәргә тиеш, шулай булмаса аның нигә кирәге бар, - ди Равил Җиһаншин.



Казансуның ярларын ныгытуга акчалар федераль казнадан бүленгән булса, төзекләндерү “Казан” җитештерү-төзелеш берләшмәсе инвестицион проекты. Моңа 1 миллиард сумнан күбрәк акча тотылган инде. Әмма төгәл чыгымнарны эшләр төгәлләнгәннән соң гына исәпләп чыгарып булачак, дип белдерде Казан җитештерү-төзелеш берләшмәсе генераль директоры.

Хәзерге вакытта Киров һәм Ленин дамбалары арасы участогында эшләр башланган. Биредәге яр буен ныгыту корылмаларын реконструкцияләү эшләре 2015 елның маенда тәмамланыр дип көтелә. Гомумән алганда, Кремль яр буе Кече көймәләр буенча дәүләт инспекциясеннән алып Миллениум күперенә кадәр, 5 километрга сузылыр дип көтелә. Әмма әлегә соңгы участокны ямьләндерүгә акчалар юк. Равил Җиһаншин сүзләренчә, хәзерге вакытта спонсорлар эзлиләр.



Проект буенча биредә дә Кремль буендагы кебек ял зонасы - җәяүлеләр һәм велосипедчылар өчен юллар, утыргычлар һәм фонтаннар булыр дип көтелә. Әмма быел мондый эшләргә чират җитмәс, мөгаен. Эшләр яр буен ныгыту белән генә чикләнәчәк.

**Гүзәл НАСЫЙБУЛЛИНА**

Укылган **184** мәртәбә Соңгы үзгәртү Пәнҗешәмбе, 12 Март 2015 21:14